СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**Р Е Ш Е Н И Е**

**К А Р А Р**

2023 елның 14 июленнән

№85

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, 2022 елның 12 апрелендәге законлы көченә кергән Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегенең 2015 елның 26 февралендәге 78 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә.

6 пунктның «В» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән

артса, «Интернет» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында законнарда билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: https://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә https://mendelevsk.tatarstan.ru. «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе Р.А.Сафин